СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЗАЙ-КАРАТАЙСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЗӘЙ-КАРАТАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

26 марта 2021ел

№ 3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге «Зәй-Каратай авыл җирлеге «муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 43 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының " Зәй-Каратай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» һәм Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында” Татарстан Республикасы Законына үзгерешләр кертү турында” 2020 елның 26 декабрендәге Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге «Зәй-Каратай авыл җирлеге «муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 43 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының " Зәй-Каратай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 статьяның 4.15 пунктында "хезмәт кенәгәсе" сүзләреннән соң "(булганда)" сүзләре белән тулыландырырга;

6 статьяны түбәндәге эчтәлекле 6.6 пункт белән тулыландыырырга:

«6.6 Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмыйлар.»;

10 статьяда 10.1.3 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»;

20.1 статьяда 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия

фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру;».

2. Әлеге карарны Зәй-Каратай авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә; әлеге карарны Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында(leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә и татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

"Зәй-Каратай авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе М.И. Идиятова